ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «һәм әлеге Закон» сүзләрен «, әлеге Закон, шулай ук Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлары» сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«19 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди һәм социаль гарантияләре**

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди һәм социаль гарантияләре судьялар статусы турындагы федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.
2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының гомуми акчалата хезмәт хакына судьялар статусы турындагы федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә судьяның аңа бирелгән квалификация классына туры килә торган вазыйфаи оклады, айлык окладды, өстәмә түләүләр, өстәлмәләр һәм башка төр түләүләр керә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарының һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәре тиешенчә Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасарының һәм Татарстан Республикасы Югары суды судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәренә тигез.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының гомуми акчалата хезмәт хакы судьялар статусы турындагы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.»;

2) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 93-ТРЗ